ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Молодежная, д.4,
с. Старое Русское Маматкозино, 422589

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 4 нче йорт,
Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, 422589

Тел.: (84379) 33-6-31, факс: (84379) 33-6-31.

23.11.2024 №  2

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 400 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:- Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрен) төзекләндерү; (Совет урамында «Тохранов чишмәсе»н төзекләндерү), дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 147 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 74 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 74 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк»позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, авыл җирлеге башлыгы карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында үзара салымны 400 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?- Җир

асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрен) төзекләндерү; (Совет урамында «Тохранов чишмәсе»н төзекләндерү), дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa.

Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында халык җыенының нәтиҗәләрен Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Никитушкин